Афзал
Нигъмәтуллин

Кояш нигә кызара

Афзал
Нигъмәтуллин



Кояш нигә кызара?

Художнигы
БУЛАТОВ В. С.

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1982

ТУГАН ЯГЫМ

Чылтыр-чылтыр
чулпыларын
Чылтыратып төш-төштә,
Вак ташларны сөеп-
назлап
Ага безнең Ташчишмә.

Ташчишмә,
Ташчишмә... —
Салкын суы саф чишмә,
«Лимонадыңны эчмә,
Ташчишмә суын эч, мә!» —
Дип әйтерлек тәме бар,
Безнең Ташчишмәне
мактый
Барлык күрше авыллар!

Бездә күп елга-сулар,
Иксез-чиксез басулар, —
Офыкта әнә шулар
Барсы бергә тоташтан
Һава белән тоташкан...
Инде язгы яшь уҗым,
Минем буйны да узып,
Арыш булып өлгергән!
Ялкын төсенә кергән,
Алтын төсенә кергән,
Икмәк исе дә кергән! —
Бик матур кырларыбыз.
Бик матур урманыбыз!
Урманыбыз данлыклы,
Төрле-төрле җәнлекле,
Җиләкле, чикләвекле,
Язын яшел,
Җәен яшел,
Көзен сары яулыклы!
Аланнары гөмбәле!
Ул андагы гөлләре!

Әйтерсең чиккән келәм...
Урман, басуы белән,
Туган авылым, туган ягым
Үзе ул — чиккән келәм!



ЯЛ КӨНЕНДӘ

Әтием утын ваткан,
Әнием мичкә яккан:
Табада чыжлый коймак...
Эш гөрли, булсаң күмәк:
Сеңелем су китерә,
Энем идән себерә.
Мин дә эшсез утырмыйм:
Каймакка манып коймакны,
Укыйм «Башсыз җайдакә»ны.

...Каймак китапка акты.
Әти колакны тартты...

ӘЮП АБЫЙ ХӘЙЛӘСЕ

— Бәхет бирәләр, бәхет!
Күрше малае Әхәт,
Рәхмәт, Әминә, Әмин,
Равил, Рамилә һәм мин:
«Ул — затлы нәрсә микән? — дип,
— Бик татлы нәрсә микән?» — дип,
Йөгердек тизрәк чатка,
Басарга дип чиратка.
Бригадир абый Әюп,
Бәхет өләшәм, диеп,
Үзе әйткән, ди, Талип.
Без торабыз таң калып:
У-у-у! Малай, чатта халык! —
Бөтен мәктәп баласы...
Ничек җаен табасы,
Безгә дигән бәхетне, —
Безгә тигән бәхетне
Ничек каерып аласы!
Бәхет — бәрхет түгел дә...
Барыбер түзми күңелләр! —
Иң шәбе кемгә тияр?
Иң күбе кемгә тияр?

Берәү әйтә: — юньлесе аның,
Соң, билгеле, — отличницага.
Отличницага — Миңнисага!
— Миңа кирәк икәү, — ди,
Директор улы Дәүли:
— Үз бәхетемне тапмасам, — ди,
— Болары аның — запаска, — ди...

Шулай бәхет бүлештек.
Ә аннан соң көлештек...
Бригадир абый Әюп:
— Биетәләрме аю? — дип,
Авыз ерып көлә-көлә
Югары очтан төшеп килә!

Аннан ул, җитдиләнеп,
И китте соң сөйләнеп:
— Балалар, барыгыз да...
Я, бире карагыз да...
Колакларга киртләгез:
Күктән бәхет көтмәгез!

Тигезләп бүлеп кенә,
Чамасын белеп кенә,
Бәхетне аны гел генә
Бирә Туган ил генә.
Бәхет була икмәктә,
Илгә хезмәт итмәктә,—
Дип, безне Әюп абый,
Ай-вайларга карамый,
Бер рәткә тезеп-санап,
Кулга тоттырып сәнәк,
Утыртып машинага
Алып китте ышнага...

АЛАНДА

Кыз бала. Уян син, нәни томшык,
Ашык син, нәни чыпчык:
Күрәмсең, чәчәктә чык,
Әйтерсең лә көмеш чук...
Чык белән юынырсың,
Таң алдыннан уянсаң —
Чык белән юына алсаң,
Чын-чынлап чыныгырсың!

Чыпчык. Иртә ич уяныргa,
Чык салкын юыныргa, —
Тормаган ич кояш та,
Кояш уянсын башта!

Кыз бала. Син, чыпчык, бигрәк иркә...
Күр, нинди матур иртә!
Тик иртә бик тиз үтә:
Кояш чыгуын чыгар...
Чыкны да эчеп куяр,
Сөт дип эчәр томанны, —
Күрми калырсың таңны —
Җиләс аланны, чыклы
Иң-иң-иң рәхәт чакны!



САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Яңгыр явып узуга,
Ялт итеп кояш чыгуга,
Җиргә нурын сузуга,
Зәңгәр күктә күренде
Кинәт күп төсле дуга.
Бер башы төште суга,
Икенчесе — басуга.

«Күкнең гүзәл сихере —
Бу салават күпере», —

Дип эти аңлатса да,
Мин уйлыйм: — Бу —
тасма ла.
Күпер түгел, басма ла...
Ә сеңелем Гөлнур әйтә:
— Бу бит, эти, көянтә,
Бу — бик тәти көянтә...
Яңгыр күп явып
үткән —
Болытның суы беткән.
Тәти көянтә белән
Болытлар су аладыр,
Кырларны сугарадыр!..

ӨЙ САЛЫРМЫН

Күрше-тирә әбиләр
Миңа гел болай диләр:
— Айрат улым,
Әбиеңне
Ярат, улым.
Тәүфыйклы бул, — диләр,
— Бәхетле бул! — диләр.

Мин әбине яратам.
Кич аны уйлап ятам.
Әбием ялгыз яши,
Зур инде аның яше.
Өе дә бик бетәшкән,
Терәтелгән төш-төштән...

...Тышта буран котыра.
Мин әле өйдә утырам.
Балта остасы һөнәрен
Аз-маз өйрәнә торам.
Җитсен димен җәй генә...
Табып бирәр җай гына,
Балта-пычкы алырмын
Һәм урманга барырмын.
Сандугачлы иртәдә
Кисеп кайтып киртәләр,
Оста булып алырмын!
Бер матур өй салырмын!
Кемгә дисез? Әбигә!
Булмас, дисез? Ә нигә?
Колгадан өй салмыйлармы?
Бүрәнәләр сайлыйлармы?
Мин шул әле кечкенә.
Җитмәс димен көч кенә...
Юкса, мин дә беләм инде:
Авылларда әле өйне
Бүрәнәдән салалар.
Таш пулатлар — калада.

Өй салуның ние бар —
Чутлыйсы да мүклисе...
Бүрәнәсен киртлисе,
Салдырасы кайрысын...
Үтми башласа балта,
Әйбәтләп аны башта
Як-ягыннан кайрыйсы.
Аннан... аласың ышкы,
Аннан, аласың пычкы...

Бер, ике, өч —
Бетте-китте эш...
...Мүк урынына түшим
мамык,
Талчыбыгы — «бүрәнә»·
Әлегә мин... чыбыклардан
Өй салырга өйрәнәм!

ҚАЕШЛАР

Абыемның солдат каешы бар!
Шундыйны дустым
Вил тагып йөрсә,
Сугыш турында
Кинолар күрсәм,
Я «солдат-солдат»
Уйнадым исә,
Шул каеш минем
Исемә төшә.

Әтиемнең дә... бил каешы бар...
Футбол типкәндә
Күлмәк ертылса,
Укытучы апам
«2»ле куйса,
Энемне кайчак
Елаттым исә,
Шул каеш минем
Исемә төшә...

АЙ

Бигрәк шук малай —
Яңа туган Ай.

Ай-яй биектән —
Балкон-болыттан,
Ул, батыраеп,
Бераз кәпрәеп,
Күлгә төбәлгән.
Күл дә түбәннән
Айга текәлгән.
Кисәтә килгән:
«Сак кылан!» — дигән...

Ә Ай тик көлгән:
— Сикерәм! — дигән,
— Су керәм! — дигән.

Уйнаудан, кызып,
Уйлаудан узып,
Сикерде Ай!
Батты бугай...
Ай!

...Ай сикерми, әлбәттә.
Сикермәве әйбәт тә.
Ай суда йөзә белми, —
Ул моны үзе белми...
Ә җир-әнкәсе белә,
Айны ул шуңа күрә,
Сак кына, ипләп кенә,
Җайлап җитәкләп кенә
Күк-диңгездә йөздерә.
«Тирәнгә» дә җибәрми,
Түбәнгә дә җибәрми!

Йөзү бит ул файдалы:
Йөзә торгач, Ай да әле
Туп кебек тулып кына,
Түгәрәк булып кына
Тазарып үсеп җитәр!

ҚОЯШ НИГӘ ҚЫЗАРА

Қояш Айга карый.
Айда тәртип — ярый!
Җиргә карый аннан,
Өстән карый, яннан,
Уңнан, сулдан карый:
Җирдә тәртип — ярый!

...Юлдан атлый шат
Бари.
Қояш аңа да карый.
Бари да пөхтә — ярый!

...Кояш карый Зыяга.
Чү? Әллә инде ояла? —
Ап-ал була, кызара...
Офык артына уза да
Тизрәк күздән югала...

ҠАЕН



Өй алдыбызда
Үсә дускаем —
Миннән бер-ике
Яшькә зур каен.

Мин суга китсәм,
Кул болгап кала.
Кире кайтканда
Шаяртып ала:
Сулы чиләккә
Яфрагын сала!

КУРАЙ АЛЫП БЕР СЫЗДЫРСАМ

Сызылып-сызылып, алсуланып таң атканда,
Җем-җем итеп чәчәкләрдә чык ятканда,
Сөенә-сөенә кояштан да иртән торсам,
Курай алып, кыр яңгыратып бер сыздырсам,
Бөдрә башкаен иеп, җил искән саен,
Тыйнак кына сәлам бирер миңа каен.

...Табигатьнең сихри җырын отып торсам,
Ә аннан соң курай алып бер сыздырсам,
Тау башыннан урман йөгреп төшәр кебек...
«Әпипә»гә сикереп биеп китәр кебек...
Бар дөньяда бәхетсезлек бетәр кебек.
Әтием дә ау мылтыгын сүтәр кебек...

ЭЧТӘЛЕК

Туган ягым 2
Ял кәнендә 4
Әюп абый хәйләсе 5
Аланда 7
Салават күпере 8
Өй салырмын 10
Каешлар 12
Ай 12
Кояш нигә кызара? 14
Каен 15
Курай алып бер сыздырсам 15

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен

Нигматуллин Афзал Агдамович

ОТЧЕГО КРАСНЕЕТ СОЛНЦЕ?

Стихи

(на татарском языке)

Рецензенты *Ш. Маннапов.* Редакторы *К. Котдусова.* Художество редакторы *Г. Трифонов.* Техник редакторы *Ф. Абдрахманова.* Корректоры *Р. Хәмидуллина.*

ИБ № 2624

Наборга бирелде 26.01.82. Басарга кул куелды 5.10.82. Формат $60 \times 90^1/_{16}$. Типография кәгазе № 1. Гарнитура литературная. Печать высокая. Басма табагы 1,0. Усл. кр. отт. 1,5. Учет.-изд. 1,2. Заказ У-37. Тираж 10000. Бәясе 5 тиен.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

ББК 84.3 Тат.
Н53

Н $\frac{70801-271}{М\ 132(03)-82}$ 178—82

© Татарстан китап нәшрияты, 1982.

5 тиен